**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Сухояшского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**
ул.Школьная, д. 4-2, село Большой Сухояш, Азнакаевского муниципального района, 423325
Тел. (факс) 34-6-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Сукаеш авыл җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**
Мәктәп урамы, 4-2, Зур Сукаеш авылы, Азнакай муниципаль районы, 423325,Тел. (факс) 34-6-16

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«16» ноябрь 2020 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 2021 елның 26 ноябрь көнне Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 26 ноябрь 2021 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Курай Елга авылы, Курай елга ур., 21 йорт, Бөек Ватан сугышында катнашучы авылдашлар истәлегенэ куелган обелиск янында ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2021 елның 17 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Зур Сукаеш авылы, Мәктәп урамы, 4-2 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Курай Елга торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Курай Елга торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда Сукаеш авыл җирлеге Курай Елга торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында

катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә һәм 2 Төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәннәрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Курай Елга авыл җирлегендә урамнарны яктырту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампаларны, яктырткычларны, электр җиһазларын һәм махсус җайланмаларны сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча хезмәт күрсәтү).

« РИЗА»　　　　　　　　　　«КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Курай Елга авылы, Курай елга ур., 22-23 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сукаеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык:　　　　　　　　　　З.Җ. Закирова